**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№12175**
**15.12.2023**

Башкарма комитетның 2023 елның 6 июлендәге 5870 номерлы Карары белән расланган Шәһәр элемтәсендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5,25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 6 июлендәге 5870 номерлы Карары белән расланган Шәһәр элемтәсендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия турында мәгълүматлар, Шәһәр Советының бюджет турында Карары (Шәһәр Советының шәһәр бюджеты турында Карарга үзгәрешләр кертү турында Карары) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (алга таба – шәһәр сайты) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында урнаштырыла.»;

2) 3 бүлекнең исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. Хисаплылыкка таләпләр һәм субсидия бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешенә контрольне (мониторингны) гамәлгә ашыру турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык»;

3) 4 кушымтага түбәндәге эчтәлектәге 7.5 пункт өстәргә:

«7.5. Шартнамә, шартнамәгә өстәмә килешү, шул исәптән шартнамәне өзү турында өстәмә килешү (кирәк булганда) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән типовой формалар нигезендә Башкарма комитет һәм субсидия алучы арасында, шулай ук башка оешма арасында төзелә.

Субсидия бирү турында шартнамәдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмауга китерә торган элек бирелгән бюджет йөкләмәләренең лимитлары кимегән очракта, субсидия бирү турында шартнамә яклары арасында шартнамәнең яңа шартлары килештерелә яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешә алмаган очракта, шартнамәне өзәләр.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов